СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
сАлан-Бексер, ул. Центральная, 19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19

Тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**06 февраль 2024 ел.** **№ 95**

**2017 елның 24 октябренда кабул ителгән 96 номерлы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру Тәртибе” турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законга, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елның 24 октябренда кабул ителгән 96 номерлы “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру Тәртибе” (Советның 19.08.2022 № 61 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6 нчы пунктта “кадрлар эше һәм муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча белгеч” сүзләрен “башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары (сәркатибе) сүзләре белән алыштырырга.

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр (алдагы еллар өчен дә) рәсми сайтта урнаштырылганнан соң бу

муниципаль вазыйфалар биләүче затлар әлеге вазыйфада эшләгән дәвердә барлык кешеләр өчен дә ачык булырга тиеш”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина